ГОСУДАРСТВЕННЫЙ КОМИТЕТ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН ПО ЗАКУПКАМ

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ САТЫП АЛУЛАР БУЕНЧА ДӘҮЛӘТ КОМИТЕТЫ

**ПРИКАЗ** **БОЕРЫК**

27.05.2024 № 09-07-11

Казан шәһәре

Татарстан Республикасы Сатып алулар буенча дәүләт комитетының 2015 елның 6 июлендәге 09-16-88 номерлы боерыгы белән расланган Татарстан Республикасы Сатып алулар буенча дәүләт комитетының дәүләт граждан хезмәткәрләренең хезмәт тәртибенә куелган таләпләрне үтәү һәм мәнфәгатьләр конфликтын җайга салу буенча комиссия турында нигезләмәгә үзгәрешләр кертү турында

«Федераль дәүләт хезмәткәрләренең хезмәт тәртибенә куелган таләпләрне үтәү һәм мәнфәгатьләр конфликтын җайга салу комиссияләр турында» Россия Федерациясе Президентының 2010 елның 1 июлендәге 821 номерлы Указы нигезендә б о е р а м:

Татарстан Республикасы Сатып алулар буенча дәүләт комитетының 2015 елның 06 июлендәге 09-16-88 номерлы боерыгы белән (Татарстан Республикасы Сатып алулар буенча дәүләт комитетының 2016 елның 23 мартындагы 09-16-42 номерлы, 2018 елның 04 октябрендәге 09-05-161 номерлы, 2022 елның 30 сентябрендәге 04-05-182 номерлы, 2023 елның 05 апрелендәге 04-05-44 номерлы, 2023 елның 18 сентябрендәге 09-07-10 номерлы боерыклары нигезендә кертелгән үзгәрешләр белән) расланган Татарстан Республикасы Сатып алулар буенча дәүләт комитетының дәүләт граждан хезмәткәрләренең хезмәт тәртибенә куелган таләпләрне үтәү һәм мәнфәгатьләр конфликтын җайга салу буенча комиссия турында нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

3 пунктның «а» пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«а) Дәүләт комитетының дәүләт граждан хезмәткәрләре (алга таба - дәүләт хезмәткәрләре) тарафыннан коррупциягә каршы көрәшү максатларында «Коррупциягә каршы көрәшү турында» 2008 елның 25 декабрендәге 273-ФЗ номерлы Федераль закон, башка федераль законнар нигезендә билгеләнгән

чикләүләрне һәм тыюларны, мәнфәгатьләр конфликтын булдырмау яисә җайга салу буенча таләпләрне (алга таба - хезмәт тәртибенә куелган таләпләр һәм (яисә) мәнфәгатьләр конфликтын җайга салу буенча таләпләр) үтәүне, вазыйфалар башкаруны тәэмин итүдә;»;

10 пунктка түбәндәге эчтәлекле җөмләне өстәргә:

«Килешү сорау алган көннән алып 10 көн эчендә гамәлгә ашырыла.»;

16 пунктка түбәндәге эчтәлекле «е» пунктчасын өстәргә:

«е) дәүләт хезмәткәренә хезмәт тәртибенә куелган таләпләрне үтәүгә һәм (яисә) мәнфәгатьләр конфликтын җайга салу буенча таләпләрне үтәүгә каршы килә торган ул йогынты ясый алмы торган шартларның барлыкка килүе турында хәбәр итү.»;

17.4 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«17.4. Әлеге Нигезләмәнең 16 пункты «б» пунктчасы бишенче абзацында һәм «е» пунктчасында күрсәтелгән хәбәрнамәләр кадрлар эшен оештыру һәм алып бару өчен җаваплы хезмәткәр - коррупциячел һәм башка төрле хокук бозуларны профилактикалау эше өчен җаваплы зат тарафыннан карап тикшерелә, ул хәбәрнамәләрне карап тикшерү йомгаклары буенча нигезле бәяләмәләр әзерли.»;

17.5 пунктта «16 пунктның «д» пунктчасында» сүзләрен «16 пунктның «д» һәм «е» пунктчаларында» сүзләренә алмаштырырга;

17.6 пунктта:

«а» пунктчасында «16 пунктның «д» пунктчасында» сүзләрен «16 пунктның «д» һәм «е» пунктчаларында» сүзләренә алмаштырырга;

«в» пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«в) әлеге Нигезләмәнең 16 пункты «б» пунктчасы икенче һәм бишенче абзацларында, «д» һәм «е» пунктчаларында күрсәтелгән мөрәҗәгатьләрне һәм хәбәрнамәләрне алдан карап тикшерү нәтиҗәләре буенча нигезле йомгак, шулай ук әлеге Нигезләмәнең 24, 25.3, 25.4, 26.1 пунктлары нигезендә карарларның берсен яисә башка карар кабул итү өчен тәкъдимнәр.»;

18.2 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«18.2. Әлеге Нигезләмәнең 16 пункты «д» һәм «е» пунктчаларында күрсәтелгән хәбәрнамәләр, кагыйдә буларак, Комиссиянең чираттагы (планлы) утырышында карап тикшерелә.»;

19 пунктта «16 пунктның «б» пунктчасы» сүзләрен «16 пунктың «б» һәм «е» пунктчалары» сүзләренә алмаштырырга;

19.1 пунктың «а» пунктчасында «16 пунктың «б» пунктчасы» сүзләрен «16 пунктың «б» һәм «е» пунктчалары» сүзләренә алмаштырырга;

түбәндәге эчтәлекле 25.4 пункт өстәргә:

«25.4. Әлеге Нигезләмәнең 16 пункты «е» пунктчасында күрсәтелгән мәсьәләне карап тикшерү йомгаклары буенча Комиссия түбәндәге карарларның берсен кабул итә:

а) дәүләт хезмәткәре йогынты ясый алмый торган шартларның барлыкка килүе һәм аның хезмәт тәртибенә куелган таләпләрне һәм (яисә) мәнфәгатьләр конфликтын җайга салу буенча таләпләрне үти алмавы арасында сәбәп-нәтиҗә бәйләнеше булуын тану;

б) дәүләт хезмәткәре йогынты ясый алмый торган шартларның барлыкка килүе һәм алның хезмәт тәртибенә куелган таләпләрне һәм (яисә) мәнфәгатьләр конфликтын җайга салу буенча таләпләрне үти алмавы арасында сәбәп-нәтиҗә бәйләнеше булмавын тану.»;

26 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итергә:

«26. Әлеге Нигезләмәнең 16 пункты «а», «б», «г», «д» һәм «е» пунктчаларында күрсәтелгән мәсьәләләрне карап тикшерү йомгаклары буенча һәм аны кабул итүгә тиешле нигезләр булганда, Комиссия әлеге Нигезләмәнең 22 - 25.4 һәм 26.1 пунктларында каралган карарны түгел, ә башка карар кабул итәргә мөмкин. Мондый карарны кабул итү өчен нигезләр һәм сәбәпләр Комиссия утырышы беркетмәсендә күрсәтелергә тиеш.».

Председатель вазыйфаларын башкаручы И.Г.Багаутдинов